ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«14» июль 2021 ел** **№ 491**

**2021 елга муниципаль юл фонды акчасы хисабына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында юл эшләре муниципаль программасын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елга муниципаль юл фонды акчалары хисабына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында юл эшләре муниципаль программасын кушымта нигезендә раслырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Р.Р. Фазыловка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р. Мөхәрәмов

Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
14 июль 2021 ел, № 491
карары белән расланды

# 2021 ЕЛГА МУНИЦИПАЛЬ ЮЛ ФОНДЫ АКЧАЛАРЫ ХИСАБЫНА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ҖИРЛЕ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ГОМУМИ ФАЙДАЛАНУДАГЫ АВТОМОБИЛЬ ЮЛЛАРЫНДА ЮЛ ЭШЛӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ

# ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2021 елга муниципаль юл фонды акчалары хисабына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл эшләре муниципаль программасы |
| Программаны эшләү өчен нигез | 1.Россия Федерациясе бюджет кодексы<br>2.Татарстан Республикасы бюджет кодексы<br>3. «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2020 елның 27 декабрендәге 78-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.<br>4. 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына Арча муниципаль районы бюджеты<br>5. «Муниципаль юл фондын булдыру һәм муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибен раслау турында» Арча район Советының 12.10.2013 ел, № 232 карары<br>6. 2021 елга Татарстан Республикасы юл эшләре программасы («2021 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 25 декабрендәге 1187 номерлы карарына кушымта)<br>7. 2021 елда гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге юлларда юл эшләренең муниципаль программаларын гамәлгә ашыруга юнәлдерелә торган муниципаль юл фондлары ассигнованиеләре күләме<br>8. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон |
| Программаның координаторлары | 1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы<br>2. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы<br>3. «Татарстан Республикасы юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерүнең төп идарәсе» ДКУ |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүчеләр | Арча муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге |

| | |
|---|---|
| Программаның максатлары һәм бурычлары | 1. Арча муниципаль районы торак пунктларындагы күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренә керү юлларын капитал ремонтлау һәм ремонтлау, гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл эшчәнлеген тәэмин итү<br>2. Арча муниципаль районы торак пунктларының юл-урам челтәрен юллар төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау юлы белән норматив хәлгә китерү<br>3. Җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру |
| Программаның максатчан күрсәткечләре | Муниципаль юл фонды акчаларын туплау һәм тоту |
| Гамәлгә ашыру сроклары | 2021 ел |
| Программаны финанслауның чыганаклары һәм күләмнәре | 2021 елга муниципаль юл фонды ассигнованиеләре күләме 34 900 0000 сум тәшкил итә<br>Муниципаль юл фондының 2021 елның 1 гыйнварына елларга калган акчалары 146 291, 23 сум тәшкил итә<br>(Гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру).<br>Финанслау чыганаклары<br>1. Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган автомобиль һәм турыдан-туры куыло торган бензинга, дизель ягулыгына, дизель, карбюратор һәм инжектор двигательләре өчен мотор майларына акцизлар<br>2. Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә керемнәр (финанслау чыганагы варианты)<br>3. Физик һәм юридик затлардан, шул исәптән ирекле иганәләрдән керемнәр (финанслау чыганагы варианты)<br>2021 ел лимитлары - 34 900 000,0 сум<br>Ел башына калган калдыклар - 146 291,23 сум |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре | 1. Халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү<br>2. Юл хәрәкәте иминлеген арттыру<br>3. Районның инвестиция җәлеп итүчәнлеген арттыру<br>4.Хуҗалык итүче субъектларның һәм муниципаль районның |

| | |
|---|---|
| Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | тулаем социаль-икътисади үсеше |

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль юл фонды Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179.4 статьясындагы 5 пункты нигезендә формалаша һәм кулланыла.

1.2. Муниципаль юл фонды-җирле (муниципаль) әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында юл эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итү максатларында (төзү һәм ремонтлау), шул исәптән юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен, торак пунктларның ишегалды территорияләренә керү юлларын капиталь ремонтлау һәм ремонтлау чараларын гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлек бюджеты акчаларының бер өлеше.

1.3. Юл фонды акчалары максатчан билгеләнешкә ия һәм юл эшчәнлеген тәэмин итүгә бәйле булмаган ихтыяҗларга тотылырга тиеш түгел.

## 2. Юл фонды барлыкка килү чыганаклары

2.1. Юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына җирле бюджет турында Арча муниципаль районы Советы карары белән җирле бюджет керемнәренең фаразлана торган күләме суммасыннан ким булмаган күләмдә раслана:

1. Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган автомобиль бензинына һәм турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, дизель һәм карбюратор (инжектор) двигательләр өчен мотор майларына акцизлар чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы законы белән расланган дифференциацияләнгән нормативлар нигезендә Арча муниципаль районы бюджетына күчерелә.

2. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле (муниципаль) әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренә, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренә керү юлларын капиталь

ремонтлау һәм ремонтлау өчен субсидияләр рәвешендә бирелә торган керемнәр.

3.Җирле (муниципаль) әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында юл эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә шул исәптән иреклс иганәләр дә керә.

Муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләменә, хисап финанс елында фактта килеп ирешкән һәм аны төзегәндә әлеге пунктта күрсәтелгән җирле бюджет керемнәре күләме арасындагы аерманы исәпкә алып, чираттагы финанс елында төзәтмәләр кертелергә тиеш.

2.2. Юл фондының агымдагы финанс елында файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре юл фондының чираттагы финанс елындагы бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлтелә.

## 3. Юл фонды акчаларын тоту юнәлешләре

3.1. Муниципаль юл фонды акчалары түбәндәгеләргә юнәлдерелә:

1. Җирле (муниципаль) әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын проектлау, төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту;

2. Күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен, торак пунктларның күпфатирлы йортларының ишегалды территорияләренә керү юлларын капиталь ремонтлау һәм ремонтлау.

3. Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча чараларны тормышка ашыру.

3.2. 2021 елга юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен объектлы бүлү әлеге программага кушымтада чагылдырылган. Әлеге кушымталар Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең 2021 елда муниципаль юл фонды акчаларының бер өлешен юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чараларына куллану турындагы карары нигезендә формалаштырылды.

## 4. Юл фонды акчаларын тотуны тикшереп тору

Юл фонды акчаларын тотуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык

департаментының 9 нчы территориаль бүлеге, «Главтатдортранс» ДКУ башкара.

Инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Р Р.Фазылов

2021 елга муниципаль юл фонды акчалары хисабына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл эшләре муниципаль программасына кушымта

| № | Объект исеме | Км, м, кв. м | Гамәлдәге бәяләрдә капиталь керемнәр-мең сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитеты бинасына керү юлы белән парковка төзү | 156,4 кв. м | 1 483, 676 |
| 2. | Яңа Кырлай авылында тротуар төзү | 322,50 кв. м | 1 217, 965 |
| 3. | «Арчаның 8 номерлы балалар бакчасы» МББМУ парковкасын ремонтлау | 486,00 кв. м | 2 584, 127 |
| 4. | Яңасала башлангыч мәктәбе парковкасын төзү | 207,00 кв. м | 792, 389 |
| 5. | Иске Чүриле авылы мәдәният йорты парковкасын төзү | 175,00 кв. м | 223, 249 |
| 6. | “Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУ табиблык амбулаториясе парковкасын төзү | 709,00 кв. м | 2 399, 141 |
| 7. | Урта Курса ФАП парковкасын төзү | 142,50 кв. м | 450, 313 |
| 8. | Яңа Кенәр мәдәният йорты парковкасын төзү | 385,00 кв. м | 1 254, 791 |
| 9. | Арча шәһәре, М.Горький урамындагы 45 фатирлы 46 нчы торак йортның йөрү юлларын, парковкасын һәм тротуарларын төзү | 1 455,00 кв.м | 4 887, 467 |
| 10. | Арча шәһәре, Б.Урманче урамындагы 45 фатирлы 10 нчы торак йортның парковкасын, тротуарларын, йөрү юлларын төзү | 450,00 кв. м | 2 168, 064 |
| 11. | Арча шәһәре, Беренче Май урамы буенча 3 нче мәктәп-балалар бакчасына тротуар төзү | 150,00 м | 514, 848 |
| 12. | Арча шәһәре, Зур урамдагы шәхси торак йортларга альтернатив керү юллары төзү | 4 800,00 кв.м | 8 660, 945 |
| 13. | Арча шәһәре, Зур урам буенча | 493,00 кв. м | 2 506, 362 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | асфальт-бетон мәйданчыклар төзү | | |
| 14. | Арча шәһәре, Төнъяк урамының 22, 24, 26, 28, 30, 32 йортларына керү юлларын реконструкцияләү | 1 392,00 | 2 729, 561 |
| 15. | Арча шәһәре, Зәйнуллин урамында ясалма тигезсезлекләр төзү | 2 берәмлек | 109, 450 |
| 16. | Арча шәһәре, Кирпеч урамындагы суүткәргеч торбаны порталлар һәм откослар төзү юлы белән ремонтлау | 1 берәмлек | 286, 533 |
| 17. | Арча шәһәре, Бакый Урманче урамындагы суүткәргеч торбаны порталлар һәм откослар төзү юлы белән ремонтлау | 1 берәмлек | 61, 835 |
| 18. | Мәктәп балаларын йөртү өчен тукталышларны төзекләндерү:<br>1. “Арчаның 7 нче мәктәбе” МБМУ<br>2. «Нефтебаза» микрорайоны<br>3. Төбәк - Чокырча авылы | 3 берәмлек | 2 124, 003 |
| 19. | Елга исемнәре ике телдә язылган күрсәткечләр куюю | 38 берәмлек | 403, 961 |
| **2021 елга МЮФ планы буенча барлыгы (34 900,00)** | | | 34 858, 680 |
| I. | 2020 елгы бюджет йөкләмәләрен үтәү | - | - |
| II. | Кулланылмый калган акчалар хисабына БДД буенча чаралар (146, 29123), шул исәптән: | - | 146, 291 |
| 1 | Арча шәһәрендә Свердлов һәм Хезмәт урамнарын төзекләндерү | Ясалма тигезсезлекләр - 3 берәмлек | 146, 291 |
| | Бүленмәгән акчалар | | 0,00023 |
| **2021 елның 1 гыйнварына МЮФ фактта калган акчалары барлыгы** | | | 146291,23 |

Инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Р.Р.Фазылов